# Йолдыз, диләр

1. Кечкенә йолдызым,- диеп
Дәшә миңа әнием.
Кычыткан чыпчыгыдыр бу,-
Диеп әйтә әбием.

Кушымта:
Йолдыз, диләр, йолдыз, диләр,
Кай төшем соң нур чәчә?
Күкләрдә балкымасам да
Биим, җырлыйм үземчә.

2. Бөтереләм, җилләр белән
Шаярып йөргән төсле,
Күбәләк канатларында
Һавада йөзәм төсле.

3. Күңелләрем канатлана,
Гел очып йөрим шуңа.
Яратам әти-әнине,
Гомер биргәнгә миңа.